РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

26.06 2020 №277

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2012 елның 11 декабрендәге 135 номерлы «Чирмешән муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 пунктының 15 пунктчасы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2012 елның 11 декабрендәге 135 номерлы «Чирмешән муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» карарына (2019 елның 18 июлендәге 235 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына муниципаль районның электр белән тәэмин итү картасын нигезләү буенча материалларны эшләү һәм өстәү өлешендә үзгәрешләр кертүгә әзерлек буенча чаралар планын, чараларны үтәү срокларын расларга, кушымта нигезендә.

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү буенча эшләрне финанслау, муниципаль районның электр белән тәэмин итү картасы нигезләү буенча материалларны эшләү һәм өстәү өлешендә «Сетевая компания» ААҖ чаралары хисабына башкарыла.

4. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2019 елның 18 июлендәге 235 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2012 елның 11 декабрендәге 135 номерлы «Чирмешән муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзелеш, җир төзелеше, авыл хуҗалыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы урынбасары,
Советы рәисе урынбасары Г.М. Җамалетдинов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советының 2020 елның 26 июнендәге
277 номерлы карарына
1 нче кушымта

Электр белән тәэмин итү схемасын эшләү буенча чаралар планы

| №<br>п/п | Чараның исеме | Үтәү вакыты | Җаваплы зат |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан техник заданиене раслау.<br>Муниципаль районның электр белән тәэмин итү картасының территориаль планлаштыру схемасын нигезләү буенча материалларны эшләү һәм өстәү өлешендә үзгәрешләр кертү проектын эшләүгә 3 яклы контракт төзү. | 2020 ел | Шәйдуллин И.Н.<br>Кәримов И.И.<br>Сәлахов Х.С. |
| 2 | Чирмешән муниципаль районының электр белән тәэмин итү картасы белән территориаль планлаштыру схемасын нигезләү буенча материалларны эшләү һәм өстәү өлешендә территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын урнаштыру, территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында муниципаль районның | Проектны эшләүче тарафыннан җибәргәннән соң 5 эш көне эчендә | Шәйдуллин И.Н.<br>Җиһаншина Э.Б. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | электр белән тәэмин итү схемасын эшләү юлы белән. | | |
| 3 | Территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын раслау. | ТР Министрлар Кабинетының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына уңай бәяләмә кабул ителгәннән соң бер ай эчендә | Шәйдуллин И.Н. |